МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.11.2023 Казан ш № 912

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ГОРОД КАЗАНЬ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ КАЗАН ШӘҺӘРЕ
ОТДЕЛ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль
яклау министрлыгының
24.11.2023 №912 боерыгы
белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Җирләүгә социаль пособие түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 13 июлендәге 470 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №393, 08.06.2017 №349, 07.05.2018 №352, 18.09.2018 №885, 08.07.2019 №532, 14.11.2019 №1017, 09.07.2020 №491, 08.10.2020 №708, 18.08.2021 №594, от 01.10.2021 №717, 14.11.2022 №999 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Җирләүгә социаль пособие түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

2.2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.1. Дәүләт хезмәте «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлегендә (алга таба – Үзәк, Үзәк бүлеге) күрсәтелә:

үлгән кешенең яшәү урыны буенча;

154 көннән соң үле бала туган очракта ата – ата-ана яшәгән урын буенча;

әгәр үлгән кешенең билгеле бер яшәү урыны булмаса, – җирләүне башкарган кешенең яшәү урыны буенча.»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып җирләүгә социаль пособие түләү турында (түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында) карар тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы»

дәүләт мәгълүмат системасындагы (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) шәхси кабинетына җибәреп.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр телефонга смс-хәбәр итеп җибәрелергә мөмкин.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.4. Җирләү өчен социаль пособие түләү турында карар реквизитлары:

хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле органның исеме;

документның исеме;

карар кабул итү номеры һәм датасы;

гаризаның номеры һәм датасы;

алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

үлгән гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

үлем көне;

социаль пособие күләме;

алу урыны;

хезмәт күрсәтү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәре вазыйфасы;

хезмәт күрсәтү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

Җирләүгә социаль пособие түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле органның исеме;

документның исеме;

карар кабул итү номеры һәм датасы;

гаризаның номеры һәм датасы;

дәүләт хезмәтен билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр;

хезмәт күрсәтү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.»;

2.4.2 пунктны көчен югалткан дип таныргa;

2.6.1 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән үлем турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;»;

алтынчы абзацны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«3) үле бала тууы турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән белешмә һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе.»;

егерме беренче абзацны түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

«Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.»;

2.6.2 пунктның икенче, өченче, алтынчы, җиденче абзацларында «(бу абзацның таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә)» сүзләрен тщшереп калдырырга;

2.7.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларының үтәлмәве;»;

3.3.1.1 пунктның бишенче, алтынчы, тугызынчы, унынчы абзацларында «(бу абзацның таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә)» сүзләрен тщшереп калдырырга;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирләүгә социаль пособие
түләү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 3 нче кушымта

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре)
республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе

________________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында)

Җирләү өчен социаль пособие түләү турында карар

№__________ ________________________

________ №____ гариза һәм үлем турында _________ №______ белешмә нигезендә, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законга ярашлы рәвештә түбәндәгене җирләүгә социаль пособие билгеләргә

__________________________________________________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

__________________________________________________________________ күләмендә.

_______________________________________________________________________
(үлгән гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
Үлем көне: _________________________________________________________

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе белгеченең вазыйфасы

__________________________________ __________________________________;
муниципаль районда (шәһәр округында) (карар кабул иткән вазыйфа затның ФИА (соңгысы – булган очракта)

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе
_____________________________________
(муниципаль районында (шәһәр округында)

Җирләүгә социаль пособие түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

№__________ _____________________

________ №____ гариза һәм үлем турында _________ №______ белешмә нигезендә, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законга ярашлы рәвештә түбәндәгене җирләүгә социаль пособие билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителде
____________________________________________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта))
түбәндәге нигезләр буенча:
_______________________________________________________________________.

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез: ________________________________
_______________________________________________________________________.

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

Бүлекчә белгече вазыйфасы
«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге»
ДКУ №_____бүлекчәсе
__________________________________ __________________________________;

муниципаль районда (шәһәр округында)

(карар кабул иткән вазыйфа затның ФИА (соңгысы – булган очракта)

Электрон имза турында белешмәләр».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июнендәге 462 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 08.09.2014 №490, 07.06.2016 №317, 11.07.2016 №400, 08.06.2017 №348, 17.11.2017 №809, 07.05.2018 №353, 18.09.2018 №885, 08.07.2019 №532, 03.09.2019 №665, 14.11.2019 №1017, 28.02.2020 №142, 09.07.2020 №491, 08.10.2020 №708, 24.03.2021 №154, 17.11.2021 №849, 30.11.2022 №1064 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә, гражданнарга компенсация һәм пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2.6.2 пунктта:

икенче, дүртенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

өченче, бишенче абзацларда «(бу абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4.3 пунктта:

икенче, дүртенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

өченче, бишенче абзацларда «(бу абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

Регламентка 3 нче кушымтада «Ф.И.А.» сүзләрен «Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)» сүзләре белән алмаштырырга;

Регламентка 4 нче кушымтада «Ф.И.А.» сүзләрен «Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)» сүзләре белән алмаштырырга;

Регламентка 5 нче кушымтада «Ф.И.А.» сүзләрен «Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)» сүзләре белән алмаштырырга.